ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

25 ноябрь 2020 ел №2

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

2021 елда 1 теркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Җиңү торак пунктында авыл урам Яшел урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон ослекле юлларның чокырларын ямау)

-Җиңү торак пунктында меселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор ечен чапкыч, трактор өчен отвал сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җиңү торак пунктында җирлекнө яктырту һәм буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

- Җиңү торак пунктында "Җиңү кене", "Сабантуй", "Халыкара елкәннәр кене", «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова